ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.06.2023 п.г.т. Алексеевское № 197

**Башкарма комитетның 24.08.2016 ел, №371 «Алексеевск муниципаль районының гаиләләрне алмаштыручы гаиләләрдән балаларны кайтару очракларын анализлау буенча эксперт комиссиясе турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Балигъ булмаганнар эшләре буенча республика комиссиясенең 19.05.2016 ел, № 14-16 «Опекада һәм попечительлектә торучы һәм тәрбиягә алган гаиләләрдә яшәүче балаларның хокукларын яклауны тәэмин итү турында» карарының 3,4 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 5.08.2016 ел, № 7383/16 «Татарстан Республикасының гаиләне алыштыручы гаиләләреннән балаларны дәүләт оешмаларына кайтару очракларын анализлау буенча муниципаль эксперт комиссияләре төзү турында» хаты нигезендә,

**карар бирәм:**

1.Башкарма комитетның 24.08.2016 ел, №371 «Алексеевск муниципаль районының гаиләләрне алмаштыручы гаиләләрдән балаларны кайтару очракларын анализлау буенча эксперт комиссиясе турында» карарының 2 нче кушымтасын яңа редакцидә бәян итәргә (Кушымта).

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районы сайтында һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет житәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А.Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет житәкчесе** **М.Р. Гайсин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
01.06.2023 ел, № 197
карарына кушымта

**Алексеевск муниципаль районының гаиләне алмаштыручы гаиләләрдән балаларны кайтару очракларын анализлау буенча эксперт комиссиясе составы**

| № | ФИА | Вазифа |
|---|---|---|
| 1. | Гайсин Марат Рафаэлевич | Эксперт комиссиясе рәисе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 2. | Хәмзина Елена Александровна | Эксперт комиссиясе рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| 3. | Шишова Инна Сергеевна | Эксперт комиссиясе секретаре, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы |

**Эксперт комиссиясе әгъзалары**

| № | ФИА | Вазифа |
|---|---|---|
| 1. | Солдатова Марина Александровна | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Алексеевск муниципаль районында социаль яклау бүлеге башлыгы (килештерү буенча) |
| 2. | Богомолова Елена Геннадьевна | Алексеевск муниципаль районында «Балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют«Забота» ДКУ директоры (килештерү буенча) |
| 3. | Кривова Ирина Владимировна | МБМББУ «Петушок» 3 нче Алексеевск балалар бакчасы Педагог-психологы |
| 4. | Морюхова Маргарита Михайловна | Баланы тәрбиягә алган ата-ана (килештерү буенча) |
| 5. | Ярославлева Юлия Константиновна | Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районы буенча ОУУП һәм ПДН балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәсенең өлкән инспекторы (килештерү буенча) |
| 6. | Осянина Лаура Геннадьевна | Алексеевск муниципаль районында Татарстан Республикасының Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкиленең җәмәгать ярдәмчесе (килештерү буенча) |

**Башкарма комитетының
Эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**